| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

«31» июль 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 173

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен бирелүче муниципаль милке исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастыру тәртибен раслау турында

2007 нче елның 24 июлендә чыккан 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законы нигезләмәләрен тормышка ашыру, Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үсеше өчен шартларны яхшырту максатында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципаль милке исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастыру тәртибен расларга (кушымта №1).

1.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районыныңкече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципальмилке исемлеген массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру, шулай ук «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендә урнаштыруформасы (кушымта №2).

1.3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районыңкече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципальмилке исемлеген формалаштыруда кулланыла торган муниципаль милек төрләре. (кушымта №3).

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетынТатарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча Кайбицкого муниципального района буенча вәкаләтле органы итеп билгеләргә:

2.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районыныңкече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципальмилке исемлеген (алга таба - Исемлек) формалаштыру, алып бару, шулай ук бастыру буенча.

2.2. «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Федераль корпорация» акционерлык җәмгыяте белән исемлекне формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастыру өлкәсендә хезмәттәшлек.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карар үз көченә кергәннән соң бер ай эчендә 2007 нче елның 24 июлендә чыккан 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законының 4.2 өлеше таләпләре нигезендә Исемлекне массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру, шулай ук «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә .

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендә чыккан 105 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципальмилке исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырутәртибен раслау турында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасары Хәялиев Р.Р.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Советының
2019 елның «31» нче июлендә
расланган №173 нче карарына
кушымта

# Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастыру тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Тәртип кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципальмилке исемлеген (алга таба - Исемлек) формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырутәртибе кагыйдәләрен, Исемлеккә кертелә торган милеккә,әлеге милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга озак сроклы срокка бирү (шул исәптән аренда түлүвенең ташламалы ставкалары буенча) максатында таләпләрне билгели (алга таба - ярдәм инфраструктурасы оешмалары).

## 2. Исемлекне формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастыруның төп принциплары, оештыру максатлары

2.1. Исемлектә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы затлар хокукларыннан азат муниципаль милке өченче турында мәгълүматлар, (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә хокукы, кече һәм урта эшмәкәрлек-нең мөлкәти хокукларыннан кала), 2007 нче елның 24 июлендә чыккан 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законының 18 статьясы 1 өлешендә каралган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфра-структурасын тәшкил итүче оешмаларга озак срокка бирү (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) каралган, 2008 нче елның 22 июлендә чыккан 159-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне читләштерү, һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына түләүсез шартларда милеккә бирелүче, һәм Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.3 статьясы 2 пункты 6,8,9 подпунктларындагы очракларда бирелүче милек исәпкә алына.

2.2. Исемлек формалаштыру түбәндәге максатларда тормышка ашырыла:

2.2.1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек турында мәгълүматның аңлаешлылыгын тәэмин итү.

2.2.2. Шәхси милек хокукларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районыныкы булган мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга (шул исәптән түләүле, бушлай һәм аренда түлүвенең ташламалы ставкалары буенча) бирү.

2.2.3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм өлкәсендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тормышка ашыру.

2.2.4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милкендә булган муниципаль милек белән идарәнең нәтиҗәлелеген үстерү, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек үсешен стимуллаштыру.

2.3. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару түбәндәге төп принципларга нигезләнә:

2.3.1. Исемлеккә кертелә торган мөлкәт турында мәгълүматларның дөреслеге һәм бу Исемлектәге мәгълүматны актуаль саклау.

2.3.2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә Исемлекне ел саен яңартып тору (агымдагы елның 1 ноябренә кадәр).

2.3.3. Исемлекне формалаштыру һәм тулыландырганда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен яклаучы коммерцияле булмаган оешмалар, кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә үсеш институтлары белән хезмәттәшлек.

## 3. Исемлекне формалаштыру, алып бару, үзгәрешләр кертү, шул исәптән еллык тулыландыру

3.1. Исемлекне формалаштыру, алып бару, үзгәрешләр кертү, шул исәптән еллык тулыландыру Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

3.2.Исемлекне формалаштыру, алып бару Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан электрон, формада шулай ук кәгазьдә гамәлгә ашырыла. Вәкаләтле орган Исемлектәге мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.3. Исемлеккә түбәндәге критериеләргә туры килә торган милек турында мәгълүматлар кертелә:

3.3.1. Өченче затлар хокукыннан азат милек (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлекнең мөлкәти хокукларыннан кала);

3.3.2. Милеккә карата федераль законнар белән аны вакытлыча куллану, аңа ия булу, шул исәптән арендага бирү тыелмый;

3.3.3. Милек дин объекты булып тормый;

3.3.4. Милек капиталь ремонтяки реконструкция үткәрүне таләп итми, тәмамланмаган төзелеш объекты түгел, Нигезләмә белән каралган, арендага

бирелә торган капиталь ремонтяки реконструкция үткәрүне таләп итүчекапиталь төзелеш объектларыннан кала;

3.3.5. Милек агымдагы елдагы һәм чираттагы елның муниципаль милекне хосусыйлаштыру планына, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга озак сроклы нигездә ия булу һәм (яки) куллануга бирелүче исемлегенә кертелмәгән;

3.3.6. Милек авария хәлендә дип табылмаган һәм сүтелергә тиешле түгел;

3.3.7. Милек торак фондына яки торак фонды объектының инженерлык-техник тәэмин итү челтәре объектларына карамый;

3.3.8. Җир кишәрлеге шәхси хуҗалык,бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен каралмаган;

3.3.9. Җир кишәрлеге, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән кала, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясы 8 пункты 1 - 10, 13 - 15, 18 һәм 19 подпунктларында каралган җир кишәрлегенә карамый;

3.3.10. Муниципаль унитар предприятиегә, муниципаль учреждениегә хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә хокукында беркетелгән (алга таба – балансга тотучы) милеккә карата, балансга тотучыга күрсәтелгән милекне Исемлеккә кертү тәкъдим итеп, шулай ук әлеге милек белән килешүләр төзүгә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципаль милке исемлегенә кертүгә язмача килешүе белән;

3.3.11. Милеккә кулланганда үзенең үзлекләрен югалта торган, аз бәяле хәрәкәт итүче милеккә, куллану срогы биш елдан азрак булган милеккә яки Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә биш ел һәм аннан да озаграк срокка арендага бирү каралмаган, шулай ук бүленми торган әйбернең өлеше керми.

3.4. Исемлеккә мәгълүматлар кертелгән милекне муниципаль милекне хосусыйлаштыруны планы проектына яки әлеге актка өстәмәләр проектына кертү тыела.

3.5. Исемлектә милек турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милек урнашкан территория административ-территориаль бүленеше берәмлеге атамасы буенча төркемләнә, шулай ук милек төрләре буенча (шул исәптән бердәм күчемсез милек, җир кишәрлекләре , күчемле милек).

3.6. Исемлеккә милек турында мәгълүматлар кертү (шул исәптән еллык тулыландыру), шулай ук Исемлектән милек турында мәгълүматларны алып ату Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитет карары тарафыннан үз белән инициативасы белән яки Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген тәэмин итүче коллегиаль орган, Татарстан Республикасында Росимущество территориаль органы һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милек ярдәме күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары, балансга тотучылар, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен яклаучы кече

һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, коммерцияле булмаган оешмалар, кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә үсеш институтлары тәкъдиме белән башкарыла.

Исемлеккә үзгәрешләр кертү , мәгълүматларны алудан кала, муниципальн милек реестрына үзгәрешләр кертелгәннән соң ун эш көне эчендә башкарыла.

3.7. Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.6 пунктында каралган затлардан кергән тәкъдимнәрне карау, бу тәкъдимнәр кергәннән соң 30 календарь көне эчендә башкарыла. Күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

3.7.1. Тәкъдим кертелгән милек турында мәгълүматны тиешле хокукый акт кабул итеп, Исемлеккә кертү турында;

3.7.2. Тәкъдим кертелгән милек турында мәгълүматны тиешле хокукый акт кабул итеп, Исемлектән төшереп калдыру турында;

3.7.3. Тәкъдимнәрне исәпкә алуны, тәкъдим керткән затка милек Исемлегенә кертү мөмкин булмавын дәлилләп аңлаткан җавап юллап кире кагу турында.

3.8. Тәкъдимнәрне исәпкә алуны кире кагу турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

3.8.1. Милек әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында каралган критерийләргә туры килми.

3.8.2. Хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукында беркетелгән милеккә карата милекне Исемлеккә кертү турында саналып китүчеләрнең бер яки берничәсе тарафыннан ризалык булмау: баланста тотучы, балансна тотучы милке белән килешүләрне килештерү буенча вәкаләтле Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты.

3.8.3. Аренда шартнамәсе төзелергә мөмкин булган милекнең күчемле индивидуаль-билгеләнгән билгеләр булмавы.

3.9. Вәкаләтле орган күрсәтелгән милек турында мәгълүмат Исемлеккә кертелгәннән соң ике ел эчендә МСП субъектларыннан яки МСП субъектлары инфраструктурасына ярдәм оешмаларыннан түбәндәгеләр башкарылмаган булса Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милке турында мәгълүматларны алып атырга хокуклы:

- милек хокукы күчә торган һәм (яки) милек куллану буенча аукционда (конкурста) катнашуга бер заявка да булмаган;

- милек бирүне сорап бер тәкъдим (гариза) да булмаган, шул исәптән 2006 елның 26 июлендә чыккан 135-ФЗ номерлы «Конкуренцияне саклау турында» Федераль законы, Россия Федерациясе Җир кодексы белән каралган очраклар буенча аукцион үткәрелмәгән.

3.10. Түбәндәге очракларда муниципаль милек турында мәгълүматларны Исемлектән төшереп калдыру каралган:

3.10.1. Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә милеккә карата аны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мәнфәгатьләрендә куллану турында карар кабул ителгән. Бу вакытта милекне Исемлектән төшереп калдыру турында карарда милекне куллану юнәлеше һәм әлеге карарның реквизитлары күрсәтелә;

3.10.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милкенә хокук суд карары яки башка закон белән каралаган тәртиптә туктатылган;

3.10.3. Милекнең юкка чыгарылуы яки һәлак булуы аркасында.

3.10.4. Милек Россия Федерациясе канунчылыгы белән каралган тәртиптә физик  яки мораль тузуы аркасында куллануга яраксыз дип табылу;

3.10.5. Милек аның  арендаторы тарафыннан 2008 елның 22 июлендә чыккан 159-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә булган яки дәүләт милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан тарендага алынган муниципаль милекне күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре, һәм  Россия  Федерациясе канунчылыгының аерым актларына үзгәрешләр кертү» Федераль  закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының күрсәтелгән  39.3 статьясының 2 пункты 6,8,9  подпунктларында очраклар  буенча шәхси милеккә алынган.

3.11. Вәкаләтле орган Исемлектән характеристикалары максатчан кулланылышы буенча яраксызга әйләнгән  милекне төшереп калдыра, мондый милек МСП субъектына яки МСП субъектына ярдәм инфраструктурасы оешмаларына арендатор тарафыннан капиталь  ремонт һәм (яки) реконструкция ясау өчен бирелгән булса.

3.12. Вәкаләтле орган арендаторга милек турында мәгълүматларны Исмелектән төшерәчәге турында моның өчен әлеге тәртипнең 3.10 пунктында каралган нигез булырлык мәгълүматларның берсе кергәннән соң (3.10.5. пунктыннан кала) өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

4. Исемлекне бастыру һәм аңа кертелгән милек турында мәгълүматлар бирү

4.1. Вәкаләтле орган:

4.1.1.Исемлекне яки Исемлеккә үзгәрешләр кертүне «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм турында кече һәм урта эшмәкәрлек  субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен муниципаль милке исемлеген   формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастыру тәртибен раслау турында» карарына 2 нче кушымтадагы форма нигезендә расланганнан соң  «Кайбыч таннары» («Кайбицкие зори») газетасында 10 эш көне эчендә бастыруны тәэмин итә;

4.1.2. Исемлекне «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек  субъектларына һәм турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек итеп һәм (яки) куллану өчен     муниципаль милке исемлеген   формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастыру тәртибен раслау турында» карарына  2 нче кушымтадагы форма нигезендә расланганнан соң мәгълүматый-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендәге  Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында 3 эш көне эчендә бастыруны тәэмин итә (шул исәптән ачык мәгълүматлар формасында).

4.1.3.  «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль   корпорация» акционерлык җәмгыятенә Исемлекне һәм Исемлеккә кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүматны Россия Федерациясе икътисадый үсеш Министрлыгының 2016 елның 20 апрелендә чыккан 264 номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль  законының 18 статьясының  4

өлешендә күрсәтелгән дәүләт милке һәм муниципаль милек турында мәгълүматлар бирү тәртибен раслау турында» Приказы белән билгеләгән форма һәм срокларда җиткерә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Советының
2019 елның 31.07. 173 номерлы карарына кушымта 2

# КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШМӘКӘРЛЕК СУБЪЕКТЛАРЫНА һәм ҺӘМ КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШМӘКӘРЛЕК СУБЪЕКТЛАРЫНА ЯРДӘМ ИНФРАСТРУКРУРАСЫН ТӘШКИЛ ИТҮЧЕ ОЕШМАЛАРГА МИЛЕК ИТЕП ҺӘМ (ЯКИ) КУЛЛАНУ ӨЧЕН БИРЕЛҮЧЕ МУНИЦИПАЛЬ МИЛКЕ ИСЕМЛЕГЕ ФОРМАСЫ

| N п/п | объектның адресы (урнашу урыны) <1> | Күчемсез милек объекты төре; күчемле милек тибы <2> | исәп объекты атамасы <3> | Күчемсез милек турында мәгълүматлар | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Күчемсез милек объектының төп характеристикасы <4> | | |
| | | | | Тибы (мәйданы – җир кишәрлекләре, зданиеләр, биналар өчен; озынлыгы, күләме, мәйданы, тирәнлеге- корылмалар өчен; нигезендә проект документациясе озынлыгы, күләме, мәйданы, тирәнлеге - тәмамланмаган төзелеш объектлары өчен) | Фактик мәгънәсе/ Проектлау мәгънәсе (тәмамланмаган төзелеш объектлары өчен) | Единица измерения (для площади - кв. м; для протяженности - м; для глубины залегания - м; для объема - куб. м) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

| Күчемсез милек турында мәгълүматлар | | | | | Күчемле милек турында мәгълүматлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кадастр номеры <5> | | Күчемсез милекнең техник хәле <6> | Җирләр нең категори ясе <7> | Рөхсәт ителгән куллану төре <8> | | | | |
| Номер | Тибы (кадастр, шартлы, искергән) | | | | Дәүләт регистрация билгесе (булса) | Марка, модель | Чыккан елы | Милекнең составы <9> |
| 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |

| Хокукка ия булучылар өченче затлар хокуклары турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Аренда һәм бушлай куллану | Хокукка ия | Милеккә | Хокукка ия | телефон | Электрон почтасы |

| шартнамәләре өчен | | булучы атамасы <11> | чикләнгән хокук булуы <12> | булучының ИНН <13> | номеры <14> | адресы <15> |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Милеккә аренда яки бушлай куллану Шартнамәләренә хокук булу <10> | Шартнамә срогы чыгу вакыты (булган очракта) | | | | | |
| 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |

<1> Объектның адресы (урнашу урыны) күрсәтелә (Күчемсез милек өчен Бердәм күчемсез милек реестрындагы язма буенча адресы, күчемле милек өчен – адрес ориентиры, шул исәптән почта адресы, даими урнашу урыны, аны күрсәтү мөмкинлеге булмаганда - мондый объект милекчесе вәкаләтләрен башкаручы дәүләт хакимияте органы я булмаса җирле үзидарә органы урнашкан урынның тулы адресы).

<2> Күчемсез милек объектлары өчен төре күрсәтелә: җир кишәрлеге, здание, корылма, бина, бердәм күчемсез комплекс; күчемле милек өчен тибы өчен: транспорт, җайланмалар, инвентарь, башка күчемле милек.

<3> Күчемсез милек объектларының аның турында күчемсез милек Кадастрындагы мәгълүматлар нигезендә шәхси атамасы, ул булмаган очракта - объектның дәүләт (муниципаль) милек реестрындагы атамасы. Әгәр милек бүлмә булса, аның зданиедәге номеры күрсәтелә. Шәхси атамасы булмаганда, күчемсез милекнең төре күрсәтелә. Көчемле милек өчен дәүләт (муниципаль) милек реестрындагы атамасы яки техник документациядәге атамасы күрсәтелә.

<4> Төп характеристика, аның мәгънәсе һәм объектны үлчәү берәмлекләре Бердәм күчемсез милек реестрындагыча күрсәтелә.

<5> Күчемсез милек объекты яки аның өлешенең кадастр номеры күрсәтелә, ул булмаган очракта - шартлы номеры яки искергән номеры (булса).

<6> Күчемсез милек объектының техник халәте турында актуаль мәгълүматлар булган документлар нигезендә, әлеге күрсәткечләрнең берсе күрсәтелә; агымдагы ремонт кирәк; капиталь ремонт таләп итә (норматив техник хәлгә китерү өчен). Әгәр милек тәмамланмаган төзелеш объекты булса, тәмамланмаган төзелеш объекты дип күрсәтелә.

<7>, <8> Исемлеккә кертелгән күчемсез милек өчен мондый объект урнашкан җир кишәрлегенең категориясе һәм рөхсәт ителгән куллану төре.

<9> Милек составының кыскача тасвирламасы, әгәр ул башка әйберләр белән арендага бирелә торган катлаулы әйбер яки төп әйбер булса. Башка очракларда бу юл тутырыла.

<10> "Әйе" яки "Юк" дип күрсәтелә.

<11> Казна милке өчен гәвами-хокукый оештыру атамасы, хуҗалык алып бару яки оператив идарә хокукында беркетелгән милек өчен бу милек беркетелгән дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) учреждение атамасы күрсәтелә.

<12> Казна милке өчен күрсәтелә: «юк» хуҗалык алып бару яки оператив идарә хокукында беркетелгән милек өчен: «Хуҗалык алып бару хокукы» яки «оператив идарә хокукы».

<13> ИНН бары тик дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) учреждение өчен генә күрсәтелә.

<14>, <15> кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга милек арендасы шартнамәсе төзү буенча җаваплы структур подразделение яки хезмәткәрнең телефон номеры һәм электрон почта адресы.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2019елның 31.07. 173 номерлы
карарына кушымта №3

КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШМӘКӘРЛЕК СУБЪЕКТЛАРЫНА ҺӘМ КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШМӘКӘРЛЕК СУБЪЕКТЛАРЫНА ЯРДӘМ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН БАРЛЫККА КИТЕРҮЧЕ ОЕШМАЛАРГА БИРҮ ҺӘМ (ЯКИ) ФАЙДАЛАНУГА БИРҮ ӨЧЕН БИЛГЕЛӘНГӘН МУНИЦИПАЛЬ МИЛЕК ИСЕМЛЕГЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ӨЧЕН ФАЙДАЛАНЫЛА ТОРГАН МУНИЦИПАЛЬ МӨЛКӘТ ТӨРЛӘРЕ (2007 ЕЛНЫҢ 2 АВГУСТЫНДАГЫ 38-ТРЗ НОМЕРЛЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ РЕДАКЦИЯСЕНДӘ)

1. Күчемле милек: Хезмәт срогы биш елдан артык булган җайланма, машиналар, механизмнар, җиһазлар, инвентарь, инструментларнең техник хәле, икътисадый характеристикалары һәм мораль тузуын исәптә тотып эксплуатациягә яраклы милек;

2. Инженерлык-техник тәэмин итү челтәренә тоташтырылган һәм транспорт инфраструктурасы объектларына керү мөмкинлеге булган күчемсез милек объектлары;

3. Аренда шартнамәсе буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына бирелгән һәм срогы биш елдан артмаган милек;

4. Размерлары Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы белән билгеләнгән чикләрдәге җир кишәрлекләре, авыл хуҗалыгы юнәлешендәге җирләр, шул исәптән Россия Федерациясеканунчылыгы нигезендә инвестицион проектлар тормышка ашыруга каралган җирләр, шулай ук дәүләт милекчелеге чикләнмәгән, вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкара торган җирләр;

5. Ремонт һәм реконструкция кирәк булган зданиеләр, корылмалар һәм биналар, тәмамланмаган төзелеш объектлары, шулай ук инженерлык-техник тәэмин итү челтәренә тоташтырылмаган һәм транспорт инфраструктурасы объектларына керү мөмкинлеге булмаган күчемсез милек объектлары.